РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«29» сентября 2022г. с. Тюлячи № 185

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 апрелендәге 263 номерлы «Теләче муниципаль районы бюджет өлкәсендә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларда эшләүчеләрнең хезмәт хакларын түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфа окладларын арттыру турында»2022 елның 22 августындагы 878 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренә түләүне тәртипкә китерү максатларында, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 апрелендәге 263 номерлы « Теләче муниципаль районы бюджет өлкәсендә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларда эшләүчеләрнең хезмәт хакларын түләү шартлары турында» карарына (12.10.2020 № 439, 02.03.2022 № 30 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктының өченче абзацын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«- аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре муниципаль берәмлекләрдә аерым бюджет өлкәсен оештыруның структур бүлекчәсе җитәкчесенең вазыйфаи окладлары буенча берничә мәртәбә исәпләп чыгарыла, аларга Теләче муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый, ул 11958,0 сум тәшкил итә;».

1.2. Карарның 5 пунктының өченче абзацын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«- хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән төнлә эшләгән өчен (22 сәгатьтән 6 сәгатькә кадәр);».

2. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасы рәисе Р.Р. Яхинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин